| | |
|---|---|
| СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 07 август 2023 ел | № 77 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеш кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Авыл җирлегенә җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча вәкаләтләр тапшыру турында" Татарстан Республикасы Балтач район Советының 23.03.2023ел, 176 нчы номерлы карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы 2013 елның 31 маендагы 78 нче номерлы Карадуган авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре”нә (13.12.2016 №38; 21.06.2018 №76; 29.08.2018 №80; 12.11.2021 №34; 28.04.2023 №72 үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 35.1 маддәсенең Шәхси торак йортлар белән төзелеш зонасы Ж-1 өлешенең Файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төрләре пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«-кибетләр».

2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/ хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Карадуган авыл җирлегендә төзекләндерү, төзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев